КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 февраль г.Казань № 162

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь, 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче; 2016 ел, 20 февраль, 106 нчы; 2017 ел, 3 июнь, 335 нче; 2018 ел, 1 сентябрь, 742 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 976 нчы; 2021 ел, 21 июль, 630 нчы; 2021 ел, 15 сентябрь, 877 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1355 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында нигезләмәнең 2 пунктында «федераль башкарма хакимият органнары» сүзләрен «федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары,» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәнең 3 бүлегендәге унберенче абзацында «башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары» сүзләрен «муниципаль берәмлекләр» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин